Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Яңа Троицкий авыл Советы

КАРАР

24 июнь 2025 ел № 123

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Яңа Троицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Яңа Троицкий авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Троицкий авылы, Совет ур., 10 йорт, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1 йорты торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында аны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яңа Троицкий авыл
Җирлеге башлыгы Л.И. Горбунова